# Кереш сүз

Моннан берничә ел элек "Русча-татарча музыкаль терминнар сүзлеге" дөнья күргән иде. Ул сүзлек таралып бетте. Беренче тәҗрибә буларак эшләнсә дә, бездә генә түгел, чит илләрдә дә аннан файдаландылар һәм хәзер дә файдаланалар. Әлбәттә, бу юнәлештә эшне дәвам итү мөһим. Чөнки музыка һөнәренә өйрәтү өчен махсус милли мәктәпләр ачу мәсьәләсе дә, яшь буынга музыкаль белемне туган телебездә бирү зарурлыгы да көн тәртибендәге актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә.

Соңгы 10-15 ел татар теленең сүзлек фонды һәм терминологик системасы нык баеды, төрле тармакларга караган күп санлы сүзлекләр дөнья күрде, телебезгә хас сүзьясалышы мөмкинлекләре киңрәк ачылды. Табигый, музыкаль терминнарны эшкәртү, яктырту юнәлешендә дә берникадәр эш башкарыла. Күренекле сәнгать эшлеклеләребез Җ. Фәйзи, М. Нигъмәтҗанов, З. Хәйруллина, Ә. Абдуллин, Г. Зәйнашева һ.б. шундыйларның татар музыка терминнарын төзү буенча алып барган игелекле эшчәнлеген Р. Хәлитов, Г.М. Макаров, Ш. Монасыпов кебек галимнәр нәтиҗәле дәвам итәләр.

Әмма бу өлкәдә эшләнәсе эшләр күп әле. Татар музыкасы белгечләре хәзерләү олы да, авыр да хезмәт. Шулай да бу өлкәдә безнең фән кандидатлары шактый: А. Абдуллин, Ч. Бәхтиярова, А. Хәйретдинов, М. Нигъмәтҗанов, Н. Әлмиева, Р. Халитов, А. Алмазова, Т. Алмазова, Ф. Шәмсетдинова, Ф. Салитова, М. Шәмсетдинова, З. Салехова, Г. Сайфуллина, Г. Гобәйдуллина һ.б. Танылган музыка белгече З. Сәйдашева уңышлы рәвештә докторлык диссертациясе яклады. Менә мондый сыйфат үсеше безнең музыка мәдәниятебезнең фәнни юнәлештә алга китүе турында сөйли, халкыбызның, күңел кылларының гына түгел, фәһем сәләтенең дә алгарышы өчен бай потенциалы бар икәнен күрсәтә.

Татар музыкасы тарихы, аның күрше тугандаш һәм тугандаш булмаган халыклар музыкасы белән бәйләнеш төрләре (генетик, үзара тәэсир итешү һ.б.), уен кораллары исемнәренең килеп чыгышы, шәкелләнү юллары һ.б.

шундый бик күп мәсьәләләр һаман да өйрәнеләсе, тикшерелергә тиешле бурычлар булып кала киләләр.

Шушы контекстта иң әһәмиятле гамәли мәсьәләләр түбәндәгеләр: аеруча сәләтле балаларны табу, аларның таланты гамәлгә ашсын өчен кирәкле шартларны тудыру, яшь буынны музыканың сихри дөньясына алып керү, алар күңеленә-йөрәгенә татар музыкасы яңгырашын, милли аһәңне салу һ.б.

Яшь буынга милли белем бирү турында фикер йөрткәндә, милли аһәңне балаларга сеңдереп калу аеруча әһәмиятле икәнен истә тотарга кирәк. Башлангыч белемне үз туган телендә, үз көе, үз җыры, үз фольклоры аша, үз шигърияти рухы катнашлыгында алган бала, кая гына барса да, нинди генә шартларга юлыкса да, үз халкының тугрылыклы улы булып калыр. Бала вакыттан кергән аһәң инде гомер буе аны туган милләте белән бәйләнештә тотар. Ана теле ул үзе дә моң бит. Һәр телнең үз яңгырашы, үз милли аһәңе, җыеп әйткәндә, үз музыкасы бар. Тел белән музыканы икесен бергә, бер-бөтен итеп карарга кирәк һәм алар безнең халкыбыз өчен бергә җигелеп эшләргә тиешләр.

Ә бит безнең халкыбыз да, телебез дә бик борынгы. Америкадагы иң борынгы җирле халыкларның (индеецлар, ацтеклар, майя һ.б.) телендә безгә ачык аңлаешлы сүзләр табылуы татар теленең борынгы тарихы бик еракка барып тоташуын фаразларга мөмкинлек бирә, кызганычка каршы, әле бу сораулар тиешенчә өйрәнелеп җитә алганы юк.

Татар теле – халыкара телләрнең берсе. Моны ЮНЕСКО да таный һәм халыкара телләр исемлегендә татар теле 14 нче урынга куелган. Менә мондый фактлар мөстәкыйль дәүләтчелеге булмаган татар халкы өчен гаҗәеп зур һәм югары бәя.

Татар теле ул – фән теле дә, дипломатия теле дә. Ул музыка теле дә булырга тиеш. Париж консерваториясе француз телендә, Берлин консерваториясе алман телендә, Мәскәү шәһәрендәге консерватория рус

телендә булган кебек, Казан консерваториясе дә үз милли телебездә булырга тиештер.

Музыкаль терминнарны үз телебезгә тәрҗемә итәргә тырышу музыка сихриятен туган телдә аңлату-сеңдерү изге эш дигән караштан чыгып эшләнә. Әле тәкъдим ителә торган сүзлек, эчтәлеге-күләме ягыннан гына түгел, бәлки татарча тәрҗемә ителгән атамаларның күләме белән дә бераз баетылган. Шулай да, төзүчеләр канәгатьләнүдән бик ерак тора. Бу сүзлекне дә билгеле бер чордагы тәҗрибә дип саныйбыз, аны баетуда, камилләштерүдә музыка һәм тел белгечләре, музыка укытучылары һәм башкаларның киң һәм актив катнашуы кирәк дип саныйбыз.

Сүзлек бу юлы да Ю.В. Келдыш редакциясендә чыгарылган 6 томлык "Музыка энциклопедиясе"нә (Мәскәү, Совет энциклопедиясе нәшрияты, 1975-1982 еллар) нигезләнеп төзелде. Әлбәттә, музыка укытучыларының иҗтиһатлы эшчәнлеге үзенчәлеген истә тотып, сүзлек составы тематик яктан бераз киңәйтелде.

Сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылды. Музыкаль терминнарның килеп чыгышын яктырту өчен, аларның чыганак телдәге эквивалентлары да китерелде. Бу исә кайбер терминнарның эчтәлеген ачыграк чагылдыру өчен дә бик әһәмиятле. Татарча өлешендә тәкъдим ителгән тәрҗемәләрнең кайберләре бәхәс тә тудырырга мөмкин (ләкин искә төшерик: протокол сүзенең тәрҗемәсе буларак кабул ителгән һәм хәзер барыбыз өчен бик аңлаешлы булган беркетмә сүзе дә кайчандыр, һичшиксез, сәер булган). Төп сүздән соң аның нигезендә ясалган аналитик төзелмәләр, ирекле яки тотрыклы сүзтезмәләр мөмкин кадәр тулы вариантта кызыл юлдан китерелде. Кайбер терминнарга җәя эчендә аңлатмалар да бирелде.

Бәяләмәчеләрнең эшлекле тәкъдимнәрен кабул итеп, аларның искәртмәләрен мөмкин кадәр үтәргә тырыштык. Без Нурмөхәммәт кызы Земфира ханым Сәйдәшевага, Лев улы Александр әфәнде Маклыгинга һәм Фаяз кызы Фирая ханым Гаффаровага рәхмәтләребезне белдерәбез.